**ГЛАВА РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 11 марты Балык Бистәсе штп. № 54Бк

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының мәдәният һәм мәгариф өлкәсендәге оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатына бәйсез бәяләү үткәрү буенча Иҗтимагый совет турында Нигезләмәне раслау хакында

2017 елның 5 декабрендәге “Мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге оешмалар һәм медик-социаль экспертиза федераль учреждениеләре тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатына бәйсез бәяләү үткәрүне камиллэштерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 392-ФЗ номерлы Федераль закон, 2018 елның 13 июлендәге “Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 55-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып, социаль хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын күтәрү, гражданнарның ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алу, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен яклау максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының мәдәният һәм мәгариф өлкәсендәге оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатына бәйсез бәяләү үткәрү буенча Иҗтимагый совет турында Нигезләмәне расларга (кушымта №1).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Нигезләмәнең үтәлешенә контрольлек итүнеТатарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.К.Вафинага йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башлыгы карарына
кушымта №1

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының мәдәният һәм мәгариф өлкәсендәге оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатына бәйсез бәяләү үткәрү буенча Иҗтимагый совет турында**
**Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының мәдәният һәм мәгариф өлкәсендәге оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатына бәйсез бәяләү үткәрү буенча Иҗтимагый совет (алга таба – сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы каршындагы Татарстан Республикасында гражданнарның мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфаты турында мәгълүматтан файдалану хокукын тормышка ашыру, аларның эшчәнлеген камилләштерү белән бәйле мәсьәләләрне караучы, шулай ук әлеге Нигезләмәдә күздә тотылган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы киңәшмә органы булып тора

1.2. Үз эшчәнлегендә сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм күрсәтмәләре, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары һәм күрсәтмәләре, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы Законнары, Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм күрсәтмәләре, Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарлары һәм күрсәтмәләренә, муниципаль хокукый актларга, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый советның мәдәният, мәгариф өлкәсендәге оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтүләр сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен һәм аларның эшчәнлеген яхшырту буенча тәкъдимнәрне үз эченә алган карары Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан аларның кергән датасыннан бер ай эчендә мәҗбүри каралырга һәм мәдәният, мәгариф өлкәсендәге оешмалар эшчәнлеген камилләштерү буенча чаралар эшләгәндә һәм аларның җитәкчеләренең эшчәнлеген бәяләгәндә исәпкә алынырга тиешле.

1.4. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет әгъзалары үз эшчәнлекләрен җәмәгать башлангычы тәртибендә гамәлгә ашыралар.

1.5. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет үз эшен граждан җәмгыяте институтларының, дәүләт хакимиятенең башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары, гаммәви мәгълүмат чаралары вәкилләренең үзара кызыксынуы нигезендә гамәлгә ашыра.

1.6. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет эшчәнлеге турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба — “Интернет” челтәре) рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

## 2. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый советның максатлары, бурычлары һәм вәкаләтләре

2.1. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет эшчәнлегенең төп максатлары булып тора:

- мәдәният һәм мәгарифнең муниципаль оешмалары, Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан һәм муниципаль берәмлек бюджетларының бюджет ассигнованиеләре хисабына мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә хезмәт күрсәтүче бүтән оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатына җәмәгатьчелек контролен көчәйтү;
- тиешле өлкәдә ачыклык, законлылык һәм профессиональлек принципларын үстерү.

2.2. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый советның бурычлары булып тора:

- мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә хезмәт күрсәтүче оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатына бәйсез бәяләү уздыру;
- мәдәният һәм мәгариф өлкәсендәге оешмалар эшчәнлеген камилләштерү буенча тәкъдимнәр хәзерләү;
- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан карарлар кабул ителгәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу механизмын камилләштерү;
- мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә хезмәт күрсәтүче оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфаты турында җәмәгатьчелекнең мәгълүматлылыгын күтәрү.

2.3. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет аңа йөкләнгән бурычлар чикләрендә:

- сыйфатка бәйсез бәяләү уздырыла торган оешмаларның исемлеген аныклый;
-эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу турындагы документация проектларын, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә хезмәт күрсәтүче оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфаты турында мәгълүмат җыйнау һәм гомумиләштерүне гамәлгә ашыручы оешма тарафыннан төзелгән дәүләт контракты проектын карауда катнаша (алга таба – оператор);
- мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә хезмәт күрсәтүче оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатына, оператор биргән мәгълүматны исәпкә алып, бәйсез бәя бирүне гамәлгә ашыра;
- мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә хезмәт күрсәтүче оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен, шулай ук алар эшчәнлегенең сыйфатын яхшырту турында тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшыра.

## 3. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет составы

3.1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Иҗтимагый советы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары мөрәҗәгате буенча күрсәтелгән мөрәҗәгать алынган көннән бер ай сроктан да соңармыйча сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый советны формалаштыра һәм аның составын раслый.

3.2. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет гражданнарның хокук һәм мәнфәгатьләрен яклау максатларында төзелгән җәмәгать оешмалары һәм инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре вәкилләре санынннан формалаштырыла.

3.3. Күрсәтелгән Иҗтимагый совет тарафыннан - мәдәният һәм мәгарифнең муниципаль оешмалары, муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан һәм

муниципаль берәмлек бюджетларының бюджет ассигнованиеләре хисабына мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә хезмәт күрсәтүче бүтән оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләү гамәлгә ашырыла.

3.4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Иҗтимагый советы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарына әлеге органнар каршында оештырылган сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет составы турында хәбәр итә.

3.5. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет составы расланган көннән 30 календарь көннән дә соңга калмыйча аның әгъзалары арасыннан сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет рәисе һәм аның урынбасары сайланачак сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый советның беренче утырышын үткәрүне оештыра. Карар ачык тавыш бирү юлы белән сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

3.6. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет рәисен яисә аның урынбасарын вазыйфадан азат итү мәсьәләсе Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органы җитәкчесе мөрәҗәгате, шулай ук сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет рәисе һәм аның урынбасарының шәхси гаризасы яки сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет әгъзалары төркеме (төркем составы сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санының биштән бер өлешеннән ким булмаган санны тәшкил иткәндә) тәкъдиме буенча сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет тарафыннан карала. Карар сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

3.7. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет рәисе совет әгъзалары арасыннан сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый советның җаваплы сәркатибен билгели.

3.8. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет составы өч ел срокка раслана.

Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый советны яңа срокка формалаштырганда аның составының өчтән береннән ким булмаган өлеше үзгәртелә.

3.9. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет составына түбәндәге затлар керә алмый:

- Россия Федерациясе һәм Россия Федерациясе субъектларының дәүләт вазыйфаларын биләүчеләр;

- Россия Федерациясе һәм Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүчеләр;

-муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын алмаштыручылар;

-2005 елның 4 апрелендәге “Россия Федерациясенең Иҗтимагый палатасы турында”гы 32-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә башка затлар.

3.10. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет үз эшенә андый бәя бирү буенча фикер уртаклашуга һәм аның нәтиҗәләрен формалаштыруга мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы җәмәгать берләшмәләре һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы вәкилләрен җәлеп итә.

3.11. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет әгъзаларының саны биш кешедән дә кимрәк була алмый.

3.12. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләре сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме

буенчаТатарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Иҗтимагый советы рәисе карары нигезендә түбәндәге очракларда туктатыла:

-Россия Федерациясенең җинаять-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә җинаять кылуда гаепләү белдерелү;

-административ арест рәвешендә аңа административ җәза билгеләнү;

-аны дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органына депутатлыкка кандидат, җирле үзидарә органының сайланулы вазыйфасына кандидат, сәяси фирка кандидатының ышанычлы заты яисә вәкаләтле вәкиле булып теркәлү, шулай ук аның Россия Федерациясендә референдум үткәрү буенча инициатив төркем составына керү очрагында.

3.13. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләре түбәндәге очракларда бетерелә:

-аның вәкаләтләренең срогы чыгу;

- аның тарафыннан сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет составыннан чыгу турында гаризасы бирелгәндә;

- сәламәтлеге буенча аның сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет эшендә катнаша алмавы аркасында;

-аңа карата чыгарылган хөкем карарының закон көченә керүе уңаеннан;

-закон көченә кергән хөкем карары нигезендә аның хокуктан файдалануга сәләтсез яисә билгесез булмаучы (юк булучы) дип танылуы сәбәпле;

-сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан күпчелеге тавышы белән кабул ителгән сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет карары буенча аның тарафыннан әхлак нормаларын тупас бозу булганда;

- сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет утырышлары эшендә игътибарга алырлык сәбәп булмыйча системалы рәвештә (өч мәртәбәдән артык) катнашмавы сәбәпле сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан күпчелеге тавышы белән кабул ителгән сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет карары буенча;

- игътибарга алырлык сәбәп булмыйча системалы рәвештә (ике мәртәбәдән артык) сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет рәисенең яки аның урынбасарының йөкләмәләрен үтәмәгән очракта сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан күпчелеге тавышы белән кабул ителгән сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет карары буенча;

- аның Россия Федерациясенең дәүләт вазыйфасына, Россия Федерациясенең дәүләт гражданнар хезмәте вазыйфасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектларының дәүләт вазыйфасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектларының дәүләт гражданнар хезмәте вазыйфасына, муниципаль вазыйфага яисә муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнүе уңаеннан;

- ике гражданлылыкка ия булу;

-Россия Федерациясе гражданлылыгының туктатылуы.

3.14. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләре туктатылу сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет әгъзасының язмача гаризасы яисә сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет рәисенең яки аның урынбасарының тәкъдиме нигезендә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.13 пунктында каралган хәлләр ачыклану очрагында Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе карарына ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла.

## 4. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары

4.1. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет әгъзасы хокуклы:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары инициативасы буенча үткәрелә торган мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә эшчәнлек алып баручы оешмаларның эшчәнлеген һәм хезмәт күрсәтү шартларын бәяләүгә кагыла торган, дәүләт серен, персональ данныйларны һәм файдалану өчен чикләнгән мәгълүматларны тәшкил итүче мәгълүматларны файдалану белән бәйле рәвештә катнашу федераль законнар нигезендә чикләнелгән чаралардан гайре, барлык чараларда (утырышлар, киңәшмәләр, “түгәрәк өстәл”ләр һ.б. да) катнашырга;

инициатива тәртибендә аналитик эш язулары, докладлар һәм бүтән мәгълүмати-анализ материаллары хәзерләргә һәм аларны сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый советка җибәрергә;

сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет рәисе аша сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый советның эш планына һәм аның утырышларын уздыру тәртибенә тәкъдимнәр кертергә;

көн тәртибендәге мәсьәләләрне карауда катнашу өчен сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет утырышларына чакырылучы затлар кандидатуралары буенча тәкъдимнәр кертергә;

сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет әгъзалыгыннан чыгарга.

4.2. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет әгъзасы бурычлы:

- сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет рәисе биргән йөкләмәләрне башкарырга;

- сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый советның әлеге Нигезләмәдә күздә тотылган эшләү тәртибен белергә һәм үтәргә;

-сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет утырышларында шәхсән катнашырга;

- үзенә йөкләнгән бурычларны хәл итү өчен сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет тарафыннан төзелгән экспертлар, эшче төркемнәре, комиссияләр, бүтән органнар эшендә катнашырга.

**5. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый советның эшен алып бару тәртибе**

5.1. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет үз эшен аның рәисе тәкъдиме буенча сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет утырышында расланган план һәм программалар нигезендә оештыра.

5.2. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет эшен планлаштыру сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет әгъзаларының, аның рәисенең һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары тәкъдимнәре буенча гамәлгә ашырыла.

5.3. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет утырышлары квартал саен кимендә бер тапкыр уздырыла. Утырышларда кабул ителгән карарлар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

5.4. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет утырышлары аларда сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет әгъзаларының кимендә өчтән икесе катнашканда вәкаләтле дип санала. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы әгъзасы утырышта шәхсән катнашу мөмкинлеге булмаган очракта, көн тәртибенә кертелгән мәсьәлә буенча үз тавышын һәм үз фикерен язма рәвештә, факсимиль яисә электрон почта аша сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советының бүтән әгъзасына тапшырырга мөмкин, ул бу хакта сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы рәисенә яисә рәис урынбасарына, яисә сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы сәркатибенә алдан хәбәр итәргә тиеш. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы утырышында катнашучы әгъзалар санына үз тавышларын сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советының бүтән әгъзаларына ышанып тапшырган сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы әгъзалары да өстәлә.

Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет карарлары гади күпчелек тавыш белән кабул ителә.

5.5. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет утырышларын аның рәисе үткәрә, ул булмаганда – сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет рәисенең урынбасары.

5.6. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет рәисе:

- сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет эшчәнлегенә гомуми җитәкчелекне гамәлгә ашыра;

- сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет утырышларын алып бара;

- сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет әгъзаларының тәкъдимнәре нигезендә Иҗтимагый советның эш планнарын әзерли, шулай ук аларга үзгәрешләр кертә һәм аларны раслауга тәкъдим итә;

- сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый советның утырышларын оештыра;

- сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет утырышының көн тәртибен раслый;

-сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет рекомендацияләрен, беркетмәләрен һәм башка документларын имзалый;

- сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет утырышларының вакытын һәм үткәрү урыннарын тәгаенли;

- сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет эшчәнлегенең үзенә йөкләнгән максатларын һәм бурычларын тормышка ашыру буенча эшчәнлеге кысаларында Иҗтимагый совет әгъзаларына йомышлар куша;

- сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет исеменнән запросларны, рекомендация, тәкъдим, аңлатмалар, мөрәҗәгатьләрне имзалый;

- сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен зарур булган башка функцияләрне гамәлгә ашыра.

5.7. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет рәисенең урынбасары:

-сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет рәисе рәсми рәвештә булмаган чагында аның функцияләрен башкара;

- сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый советның утырышларын әзерләүне оештыра;

-сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет утырышларының көн тәртибен төзи һәм аны Иҗтимагый совет рәисенә раслауга тәкъдим итә;

- сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет рәисе йөкләмәсе буенча Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле булган башка функцияләрне гамәлгә ашыра.

5.8. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый советның җаваплы сәркатибе::

-утырышларга материаллар һәм карарлар проектларын әзерләүне оештыра;

- сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет әгъзаларына Иҗтимагый совет утырышын уздыру вакыты һәм урыны, көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны кирәкле мәгълүмати-белешмә материаллар белән тәэмин итә;

- сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый советның һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының оештыру ягыннан үзара бәйләнешен (элемтәсен) тәэмин итә;

- сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет эшчәнлегенең документ-техник яктан тәэмин ителешен гамәлгә ашыра;

- сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет утырышларының беркетмәләрен рәсмиләштерә һәм кабул ителгән карарларның үтәлешенә контрольне гамәлгә ашыра;

- сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет утырышларының көн тәртипләрен төзүдә, планлаштырганда катнаша.

5.9. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет әгъзалары Иҗтимагый совет утырышларында тыңларга һәм фикер алышырга тиешле сорауларны хәзерләү өчен эшче, экспертлар төркемнәренә һәм бүтән эшче органнарга берләшергә, материалларны әзерләүгә Иҗтимагый совет рәисе урынбасары белән килештереп совет составына кермәгән белгечләрне тартырга мөмкиннәр.

5.10. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет карары буенча Иҗтимагый совет утырышларына сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет тарафыннан карала торган мәсьәләләр буенча кирәкле мәгълүматларны һәм бәяләмәләрне бирү өчен башкарма органнар, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары, коммерциячел булмаган оешмаларның, фәнни учреждениеләрнең вәкилләре, экспертлар һәм бүтән белгечләр чакырылырга мөмкин. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет әгъзалары булып тормаган гаммәви мәгълүмат чаралары вәкилләре Иҗтимагый совет чакыруы буенча утырышларда катнашырга мөмкин.

5.11. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет каравына кертелүче материаллар Иҗтимагый совет рәисе урынбасарына аларны карау күздә тотылган утырыш билгеләнгән датага кадәр ун календарь көннән дә соңармыйча тапшырылырга тиеш. Материалларны тагы да соңрак срокта тапшыру сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет рәисе яисә аның урынбасары белән килештерелергә тиеш.

5.12. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары гамәлгә ашыра.